# Иҗек

**Сүзләрне күчереп яз, сузык авазларны билгелә:**

**Тышта, җиргә, урамда.**

# Ребус

Һәр предметның беренче хәрефләрен генә алып яңа сүз яса.










# Сүзлек:

Игътибар ит – обрати внимание
Иҗек – слог
Киңрәк – шире
Өлеш – часть
Һава агымы – воздушная струя

Рәсемдәге предмет исемнәрен әйт,
иҗекләргә бүлеп яз:



# Кагыйдә

Сүзләр иҗекләргә бүленә.Сузык аваз иҗек төзи.

Һәр иҗектә берәр сузык аваз була:

ба - ла,     ал - ма.

Иҗек бер генә сузык аваздан да тора ала: ә - ни, ә - ти.

# Кагыйдә

Сүзләр бер иҗекле, ике иҗекле һәм күп иҗекле дә була: ю, ә - би, кил- де - ләр.

Бу сүзләр белән җөмләләр төзе.

# Иҗекләрдән сүзләр төзе:

Кур бак ба мак ба

ка ча шак та лык

Һәр сүздә ничә сузык аваз һәм иҗек бар?

Нинди аваз иҗек төзи?

# Бирем:

Ике иҗекле дүрт сүз уйлап яз.

# Сорауларга җавап бир:

1.Сүзне күрү белән, анда ничә ижек булуын белеп буламы?
2.Ижекне нинди аваз төзи?
3.Ижек бер сузык аваздан гына төзеләме?
4.Ижек бер тартык аваздан төзеләме?

# Җавапны тикшер:

1.Сузык авазлардан белеп була.

2.Иҗекне сузык аваз төзи.

3.Иҗек бер сузык аваздан да төзелә.

4.Иҗек бер тартык аваздан төзелми.

# Молодцы !



